ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДЫМ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Ленина, д.1а, , 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Димтамак авылы, Ленин урамы, 1а йорт,
423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 5** **15 февраль 2016 ел**

**Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга салучы законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 431 маддәсе, 2009 елның 9 февралендәге «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында»гы 14-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2015 елның 3 ноябрендәге «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы 92-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җибәрү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы белән төзелгән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен үзара хезмәттәшлек итү турындагы килешү нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгының 2016 елның 12 февралендәге 13 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җыю һәм җибәрү буенча үзара эшчәнлек регламентына һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен алар турында белешмәләр җыю регламентына таянырга.

2. Җирлек Советының, җирлек башлыгының һәм җирлек башкарма комитетының муниципаль норматив хокукый актларын район башкарма комитетына җибәрү өчен җаваплы итеп, шулай ук алар турында регистрга кертелергә тиешле белешмәләрне җирлек башкарма комитеты секретаре итеп билгеләргә.

2. Әлеге карарны Димтамак авылы, Яңа ур., 4 в йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә һәм Ютазы муниципаль районының Интернет челтәрендә урнаштырырга www.yutaza.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз контролемдә калдырам.

Димтамак
авыл җирлеге башлыгы М.М.Ямалеев

Кашапова Р.З.
4-52-37